**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МУСАБАЙ-ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«25» сентябрь 2024 ел № 13

Җирле үзидарә органнарында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм Советы җитәкчеләрен һәм хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 168 статьясы 4 елеше нигезендә һәм җирле үзидарә органнарында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм Советы җитәкчеләрен һәм хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибен билгеләү максатында,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Җирле үзидарә органнарында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм Советы җитәкчеләрен һәм хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карар 2022 елның 1 июненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе З.З. Хөсәинова

Исполнительный комитет Мусабай-Заводского сельского поселения

Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитетының 2024 елның 25 сентябрь 13 номерлы карарына 1 кушымта

Җирле үзидарә органнарында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм Советы җитәкчеләрен һәм хезмәткәрләрен командировкага җибәрү тәртибе турында нигезләмә

1. Хезмәт командировкаларына муниципаль вазифаларны биләүче затлар, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләр, учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре (алга таба – командировкага баручы) җибәрелә.

2. Командировкага баручылар эшкә алучы вәкиле (җирле үзидарә органы, муниципаль орган җитәкчесе) яки ул вәкаләт биргән зат (алга таба – эшкә алучы вәкиле яки вәкаләтле зат) карары буенча билгеле бер вакытка Россия Федерациясе территориясендә дә, чит илләр территорияләрендә дә хезмәт йөкләмәсен үтәү өчен (муниципаль хезмәтне даими үтү урыныннан, эш урыныннан тыш) хезмәт командировкаларына җибәрелә.

3. Командировкага баручыларны хезмәт командировкаларына эш бирүче җибәрә.

4. Командировкага баручының хезмәт командировкасы срогы эшкә алучы вәкиле яки вәкаләтле зат тарафыннан хезмәт йөкләмәсенең күләмен, катлаулыгын һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып билгеләнә.

5. Хезмәт командировкасына чыгу көне булып командировкага баручының муниципаль хезмәтне даими үтү урыныннан, эш урыныннан поезд, самолет, автобус яки башка транспорт чарасының китү көне, ә хезмәт командировкасыннан кайткан көн булып командировкага баручының муниципаль хезмәтне даими үтү урынына, эш урынына күрсәтелгән транспорт чарасының килү көне санала.

Транспорт чарасы 24 сәгатькә кадәр барганда, хезмәт командировкасына китү көне булып агымдагы тәүлек, ә 00 сәгатьтән соң һәм соңрак алдагы тәүлекләр санала.

Әгәр станция, пристань, аэропорт торак пункт читендә булса, станциягә, пристаньга, аэропортка кадәр бару өчен кирәкле вакыт исәпкә алына. Шул ук рәвешле командировкага баручының муниципаль хезмәтне даими үтү урынына, эш урынына кайту көне билгеләнә.

Командировкага баручының  командировкага китәсе көнне һәм командировкадан кайткан көнне хезмәткә, эшкә килү мәсьәләсе эшкә алучы вәкиле яки вәкаләтле зат билгеләгән тәртиптә хәл ителә.

6. Командировкага баручының командировкада булу срогы (командировка урынына килү датасы һәм аннан китү датасы) ул хезмәт командировкасыннан кайткач җирле үзидарә органына, эш урынына тапшырган юл йөрү документлары (билетлар) буенча билгеләнә. Юл йөрү документлары (билетлар) булмаганда, командировкага баручының хезмәт командировкасында булу срогы аның хезмәт командировкасында булу срогын раслаучы федераль дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен билгеләнгән исемлектә каралган башка документлар буенча билгеләнә.

7. Командировкага баручы командировкага җибәрелгәндә, аңа үз вазифасын һәм акчалата түләүне (уртача хезмәт хакын) саклау гарантияләнә, шулай ук түләнә:

а) командировка урынына бару һәм муниципаль хезмәтне даими үтү урынына, эш урынына кире кайту чыгымнары;

б) бер торак пункттан икенчесенә бару чыгымнары, әгәр командировкага баручы төрле торак пунктларда урнашкан берничә дәүләт органнарына (оешмаларына) командировкага җибәрелсә;

в) торак бинаны наемга алу чыгымнары;

г) даими яшәү урыныннан тыш яшәү белән бәйле өстәмә чыгымнар (тәүлеклек акча);

д) хезмәт командировкасы белән бәйле башка чыгымнар (алар командировкага баручы тарафыннан эшкә алучы вәкиленең яки вәкаләтле затның рөхсәте яки мондый чыгымнар турында хәбәр итүе шартларында башкарылса), шул исәптән муниципаль хезмәтнең югары вазифаларын биләүче хезмәткәрләр өчен торак урыннарны өченче затлар аша броньлау белән бәйле чыгымнар.

8. Командировкага җибәрелүченең хезмәт командировкасында булу чорында акчалата түләү (уртача хезмәт хакы) барлык кеннәрдә командировкага баручының муниципаль хезмәтне даими үтү урынында, даими эш урынында билгеләнгән график буенча саклана.

9. Командировкага баручы чит ил территориясенә командировкага җибәрелгәндә аңа өстәмә рәвештә түләнә:

а) чит ил паспортын, виза һәм башка чыгу документларын рәсмиләштерү чыгымнары;

б) мәҗбүри консуллык һәм аэродром җыемнары;

в) керү яки автомобиль транспорты транзиты хокукы өчен түләүләр;

г) мәҗбүри медицина иминиятләштерүен рәсмиләштерү чыгымнары;

д) башка мәҗбүри түләүләр һәм җыемнар.

10. Командировкага баручының билгеләнгән тәртиптә таныкланган вакытлыча эшкә яраксызлыгы булган очракта, аңа торак урынын наемга алу чыгымнары түләнә (командировкага баручы стационар дәвалануда булган очраклардан тыш) һәм сәламәтлек торышы буенча үзенә йөкләнгән хезмәт йөкләмәсен үтәүгә керешергә яки даими яшәү урынына кайтырга мемкинлеге булганчыга кадәр бетен вакыт дәвамында тәүлеклек акча түләнә.

Вакытлыча эшкә сәләтсезлек чорында командировкага җибәрелүчегә Россия Федерациясе законнары нигезендә вакытлыча эшкә сәләтсезлек буенча пособие түләнә.

11. Командировкага баручы командировкага җибәрелгән дәүләт органы яки оешмасы аны хезмәт урыны, кирәкле материаллар һәм җиһазлар, шулай ук барлык элемтә төрләре, командировкага баручының хезмәт йөкләмәсен үтәү өчен кирәкле транспорт чаралары белән тәэмин итә.

12. Даими яшәү урыныннан читтә яшәү белән бәйле өстәмә чыгымнар (тәүлеклек акча) командировкага баручыга хезмәт командировкасында булган һәр кен өчен, шул исәптән ял һәм бәйрәм кеннәрен кертеп, шулай ук юлда булган көннәр өчен, шул исәптән мәҗбүри тукталыш вакыты өчен түләнә, Татарстан Республикасы буенча – 300 сум, Россия Федерациясенең башка төбәкләре буенча – 700 сум, чит илләр территориясендә 2 500 сумнан артмый.

13. Командировкага баручы транспорт элемтәсе шартлары һәм башкарылган хезмәт йөкләмәсе характеры буенча көн саен даими яшәү урынына кайту мемкинлеге булган җирлеккә командировкага җибәрелгән очракта, тәүлеклек акча түләнми.

Әгәр командировкага җибәрелүче хезмәт көне тәмамлангач, эшкә алучы вәкиле яки вәкаләтле зат белән килешү буенча командировка урынында кала икән, торак бинаны арендага алу турында документлар биргәндә, бу чыгымнар аңа факттагы чыгымнар буенча түләнә.

Командировкага җибәрелүченең даими яшәү урынына көн саен кайту мәсьәләсе һәр конкрет очракта эшкә алучы вәкиле яки вәкаләтле зат тарафыннан, ераклыкны, транспорт элемтәсе шартларын, үтәлә торган хезмәт йөкләмәсе характерын, шулай ук командировка баручыга ял итү өчен шартлар булдыру кирәклеген исәпкә алып хәл ителә.

14. Торак бинаны броньлау һәм наемга алу чыгымнары командировкага җибәрелүчеләргә (аларга бушлай торак урыны бирелгән очраклардан тыш) тиешле документлар белән расланган чыгымнар буенча түбәндәге нормаларны исәпкә алып кайтарыла:

а) муниципаль хезмәтнең югары вазифаларын биләүче һәм җитәкче командировкага җибәрелгәндә бер урынлы номер бәясе буенча;

б) башка командировкага җибәрелүчеләргә стандарт бер урынлы номердан артыграк түгел.

15. Әгәр торак пунктта кунакханә булмаган очракта, командировкага җибәрелүчегә башка аерым торак бүлмә яки якындагы торак пунктта шундый ук торак бүлмә бирелә, анда яшәү урыныннан командировкага бару урынына кадәр һәм киреге транспорт белән тәэмин итү гарантияләнә.

Юлда тукталырга мәҗбүр булган очракта, командировкага җибәрелүчегә торак бинаны наемга алуның тиешле документлар белән расланган чыгымнары әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән күләмдә түләнә.

16. Командировкага җибәрелүченең командировка урынына бару һәм муниципаль хезмәтне даими үтү урынына, эш урынына кире кайту (юл йөрү документларын рәсмиләштерү, поездларда урын-җир кирәк-яракларын бирү буенча хезмәт күрсәтү буенча түләүне кертеп), шулай ук бер торак пункттан икенчесенә баруы буенча чыгымнар юл йөрү документлары белән расланган фактагы чыгымнар буенча түбәндәге нормалар буенча түләнә:

а) муниципаль хезмәтнең югары вазифаларын биләүче командировкага барганда:

һава транспорты белән – I класс билеты буенча;

диңгез һәм елга транспорты белән – пассажир йөртүче билгеләгән тарифлар буенча, әмма пассажирларга комплекслы хезмәт күрсәтү белән, люкс каютасында йөрү бәясеннән артыграк түгел;

тимер юл транспорты белән – бизнес-класс вагондарына караган югары комфортлы вагонда, ике урынлы "СВ" категорияле купеларда яки "С" категорияле вагонда бизнес-класс вагоннарына куелган таләпләргә туры килгән утыру урыннары белән;

б) муниципаль хезмәтнең төп вазыйфаларын башкаручы командировкага барганда:

һава транспорты белән – бизнес - класс тарифы буенча;

диңгез һәм елга транспорты белән – пассажир йөртүче билгеләгән тарифлар буенча, әмма пассажирларга комплекслы хезмәт күрсәтү белән ике урынлы каютада йөрү бәясеннән артыграк түгел;

тимер юл транспорты белән – югары комфортлы вагонда, эконом класстагы вагоннарга караган, дүрт урынлы "К" категорияле купелы яки "С" категорияле вагонда утыру урыннары белән;

в) муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы, өлкән һәм кече вазыйфаларын башкаручы, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре командировкага барганда:

һава транспорты белән – эконом класс тарифы буенча;

диңгез һәм елга транспорты белән – пассажир йөртүче билгеләгән тарифлар буенча, әмма пассажирларга комплекслы хезмәт күрсәтү белән дүрт урынлы каютада йөрү бәясеннән артыграк түгел;

тимер юл транспорты белән – югары комфортлы вагонда, эконом класстагы вагоннарга караган, дүрт урынлы "К" категорияле купелы яки "С" категорияле вагонда утыру урыннары белән.

16.1. Командировкага җибәрелүченең командировка урынына бару һәм (яки) муниципаль хезмәтне даими үтү урынына, эш урынына кире кайтуы өчен һава транспортын кулланганда, юл йөрү документлары (билетлар) Россия авиакомпанияләре яки башка Евразия икътисади берлеге әгъзалары булган дәүләтләрнең авиакомпанияләре рейсларына гына рәсмиләштерелә (сатып алына), күрсәтелгән авиакомпанияләр командировкага баручының командировка урынына пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырмаган очраклардан яисә бу авиакомпанияләр рейсларына йөрү документларын (билетларны) рәсмиләштерү (сатып алу) командировкага китүнең бөтен срогына аларның булмавы аркасында мөмкин булмаганда.

17. Юл йөрү документлары (билетлар) яки транспорт оешмалары биргән һәм юл йөрү документларында (билетларда) булган мәгълүматны раслаучы документлар

булмаганда, юл йөрү өчен түләү башкарылмый. Командировкага баручы хезмәткәргә станциягә, пристаньга, аэропортка кадәр юл йөрү чыгымнары бу чыгымнарны раслаучы документлар (билетлар) булганда түләнә.

18. Хезмәткәрләрнең аерым категорияләренә тимер юл һәм автомобиль вокзаллары (станцияләре), диңгез һәм елга портлары, халыкара элемтәләр (халыкара очышлар) өчен ачык аэропортлар (аэродромнар) составында оештырыла торган рәсми затлар һәм делегацияләр заллары хезмәтләре өчен түләнә. Муниципаль хезмәтнең югары вазифаларын биләүче, рәсми затлар һәм делегацияләр залларыннан файдалану хокукы бирә торган муниципаль хезмәт вазифалары исемлеге.

19. Командировкага баручыны Россия Федерациясе территориясеннән читтә хезмәт командировкасына җибәргәндә, тәүлеклек акча чит ил валютасында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән күләмдә түләнә.

20. Россия Федерациясе территориясеннән читтә хезмәт командировкасына җибәрелгән командировкага баручыга юлда булу вакытына тәүлеклек акча түләнә:

а) Россия Федерациясе территориясе буенча барганда – әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә һәм зурлыкта;

б) чит ил территориясе буенча барганда – чит илләр территориясендә хезмәт командировкалары өчен Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә һәм зурлыкта.

21. Командировкага җибәрелүче Россия Федерациясе территориясеннән чыкканда, Россия Федерациясе дәүләт чиген кичү көне тәүлеклек акча чит ил валютасында түләнә торган көннәргә кертелә, ә Россия Федерациясе территориясенә кергәндә, Россия Федерациясе дәүләт чиген кичү көне тәүлеклек акча сумда түләнә торган көннәргә кертелә.

Россия Федерациясе территориясеннән чыккандада һәм Россия Федерациясе территориясенә кергәндә, Россия Федерациясе дәүләт чиген кичү даталары командировкага җибәрелүченең паспортында, хезмәт паспортында яки дипломатик паспортында чик органнары билгеләре буенча билгеләнә.

Командировкага баручыны ике яки аннан да күбрәк чит ил территориясенә хезмәт командировкасына җибәргәндә, дәүләтләр арасындагы чикләрне кичкән көн өчен тәүлеклек акча чит ил валютасында командировкага баручы җибәрелгән дәүләт өчен билгеләнгән нормалар буенча түләнә.

22. Командировкага баручы Бәйсез Дәүләтләр Берләшмәсендә катнашучы дәүләтләр территориясенә хезмәт командировкасына җибәрелгәндә (алар белән хөкүмәтара килешүләр төзелгән, алар нигезендә документларда чик органнары тарафыннан кергән һәм чыккан ечен дәүләт чиген кичү турында билгеләр ясалмый), Россия Федерациясе дәүләт чиген кичү датасы юл йөрү документлары (билетлар) буенча билгеләнә.

Юлда мәҗбүри тоткарлык очрагында, мәҗбүри тоткарлык фактын раслаучы документлар тапшырганда, эшкә алучы вәкиле яки вәкаләтле зат карары буенча тоткарлык вакытына тәүлеклек акча түләнә.

23. Чит ил территориясенә командировкага чыккан һәм шул ук көнне Россия Федерациясе территориясенә кайткан хезмәткәргә чит ил валютасында тәүлеклек акча Россия Федерациясендә билгеләнгән тәүлеклек акчаны түләү чыгымнары нормасының 50 проценты күләмендә түләнә.

Әгәр чит ил территориясенә хезмәт командировкасына җибәрелгән командировкага баручы хезмәт командировкасы чорына кабул итүче як хисабына шәхси чыгымнарга чит ил валютасы белән тәэмин ителә икән, җибәрүче як чит ил валютасында тәүлеклек акча түләүне башкармый. Әгәр кабул итүче як күрсәтелгән хезмәткәргә шәхси чыгымнар өчен чит ил валютасын түләми, әмма аңа үз хисабына тукландыра икән, җибәрүче як аңа күрсәтелгән норманың 30 проценты күләмендә чит ил валютасында тәүлеклек акча түли.

24. Хезмәткәрләрне чит илләр территориясенә хезмәт командировкаларына җибәргәндә, торак урынын наемга алу чыгымнары тиешле документлар белән расланган факттагы чыгымнар буенча түләнә, әмма чит илләр территориясендә кыска вакытлы

хезмәт командировкаларында торак урынын наемга алу чыгымнарын түләүнең Россия Федерациясендә билгеләнгән чик нормаларыннан артмый.

25. Командировкага баручы чит илләр территориясенә командировкага җибәрелгәндә юл йөрү чыгымнары аңа Россия Федерациясе территориясе чикләрендә хезмәт командировкасына җибәрелгән тәртиптә түләнә.

25.1. Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә хезмәт командировкаларында булган чорда командировкада булучыларга:

а) акчалата бүләкләү (акчалата түләү) икеләтә күләмдә түләнә;

б) даими яшәү урыныннан читтә яшәү белән бәйле өстәмә чыгымнар (тәүлеклек акча) хезмәт командировкасында булган һәр көн өчен 8480 сум күләмендә түләнә;

в) торак бинаны наемга алу чыгымнары тиешле документлар белән расланган факттагы чыгымнар буенча түләнә, әмма тәүлегенә 7210 сумнан артмый.

26. Хезмәт командировкасында булган хезмәткәрләргә алар командировкага җибәрелгән дәүләт органнарының (оешмаларның) хезмәт вакыты режимы гамәлдә була. Әгәр командировкадагы хезмәткәр үз эшчәнлеген башкарган күрсәтелгән дәүләт органнарында (оешмаларда) хезмәт вакыты режимы җирле үзидарә органындагы, эш урынындагы хезмәт вакыты режимыннан ял көннәре ким булу белән аерылып торган очракта, хезмәт командировкасында булган вакытта файдаланылмаган ял көннәре урынына хезмәткәргә хезмәт командировкасыннан кайткач башка ял көннәре бирелә.

Әгәр командировкага баручы ял яки бәйрәм көннәрендә эшләү өчен махсус командировкага җибәрелсә, бу көннәрдә эш ечен компенсация Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.

27. Командировкага баручы хезмәт командировкасына җибәрелгәндә, аңа юл йөрү, торак урынын наемга алу һәм даими яшәү урыныннан читтә яшәү белән бәйле естәмә чыгымнарны (тәүлеклек акча) түләүгә акчалата аванс бирелә

28. Хезмәт командировкасыннан кайткач, командировкага баручы еч эш көне дәвамында билгеләнгән форма буенча хезмәт командировкасы белән бәйле рәвештә сарыф ителгән суммалар турында аванс хисабын тапшырырга һәм хезмәт командировкасына китәр алдыннан командировка чыгымнарына бирелгән акчалата аванс буенча ахыргы исәп-хисапны башкарырга тиеш. Аванс хисабына торак бинаны наемга алу, юл йөрү буенча фактик чыгымнар (шул исәптән юл йөрү документларын рәсмиләштерү, поездларда урын-җир кирәк-яраклары бирү буенча хезмәт күрсәтү буенча түләүне дә кертеп) һәм эшкә алучы вәкилә яки вәкаләтле зат рөхсәте белән башкарылган хезмәт командировкасына бәйле башка чыгымнар турында документлар теркәлә.

29. Билгеләнгән күләмнән артып киткән чыгымнар, шулай ук хезмәт командировкалары белән бәйле башка чыгымнар, шул исәптән чит оешмалар аша торак урынын броньлау буенча хезмәт күрсәтүләргә түләү белән бәйле чыгымнар (алар командировкада булучы тарафыннан эшкә алучы вәкиле яки вәкаләтле зат рехсәте белән башкрылган очракта) җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләр тарафыннан район бюджетында җирле үзидарәнең тиешле органын, муниципаль учреждениене карап тотуга каралган акчалар хисабына түләнә.

Хезмәт командировкасы белән бәйле, эш бирүче вәкиле яки вәкаләтле зат рөхсәте белән башкарылган башка чыгымнарны түләү бу чыгымнарны раслаучы документларны тапшырганда башкарыла.